

2022 ел Россия Президенты тарафыннан Россия халыкларынын мәдәни мирасы елы дип игълан ителvе дә символик мәгънәгә ия.
Бәширова Альфия Касыйм кызы - Ләмберә муниципаль районы «Аксён авыл клубы»нын 1 нче филиалы модире, сезнен очен «Татар халкынын аш-су сәнгате vз гореф-гадәтләренә бай» исеме буенча дайджест әзерләгән.      Татарлар элек-электән игенчелек белән шогыльләнәләр, шуна кvрә ашларда бортекле һәм кузаклы ашлардан он һәм торле ярмалар рәвешендә пешерелә торган ашларны актив кулланалар. Шулай ук ат һәм сыер ите дә кин кулланыла. Халыкта: «Ат итен кем ашый, торле чирләргә бирешми, чыдамлырак була», - диләр. Ат итеннән пешерелгән кыздырма - vз рецептурасын бvгенге конгә кадәр саклап калган борынгы ризык. Шулай ук татарларда казылык – ат казылыгы бар. Татарлар сот һәм сот продуктларын, нигездә, эшкәртелгән рәвештә файдаланганнар.
Татар кухнясы очен хас булган барлык тор ризыклардан ашлар һәм шулпалар аеруча хас. Ит бульонындагы токмачлы аш - токмач, бvгенге конгә кадәр кунак-ларны кабул итv вакытында мәжбvри ризык булып кала. Салма дип тә йортә халык безнен якларда.
Очпочмак (очпочмак) – татарларнын брендлы камыр ризыгы. Камыры чvпрәле. Эчлеге майлы иттән – сарык, сыер ите, каз яки vрдәк һәм суган белән әзерләнә. Бульон яки катык белән ашыйлар.
Бәйрәмнәрдә әзерләнә торган катлы бәлеш - ул гобәдия. Мордовиядә аз кеше пешерә аны. Гобәдиянен эченә кипкән корт, бvрттергән доге, ваклап тураган йомырка, йомшарткан йозем, кvрәгә, тошен алып кара жимеш яисә орек салалар.
Гобәдияне әче камырдан да, точе камырдан да әзерлиләр, майны кvбрәк салалар. Итле гобәдияне кайнар килеш икенче аш итеп бирәләр. Аны икелә тә юкарак итеп, эченә жиләк-жимеш салып та ясыйлар һәм чәй янына бирәләр.
Татар һәм башкорт уртак ашларыннан берсе, камыр тыш эченә бер яки берничә торле ашамлык салып мичтә пешерелгән кунак ашы – ул бәлеш. Эченә ит белән бәрәнге, ит белән доге, кабак, алма, һ.б. нәрсә кулланыла.
Моннан тыш, татар кухнясы чәйгә бирелә торган унайлы һәм баллы камырдан эшләнмәләргә бай. Топ бәйрәм ризыгы - чәк-чәк. Бу татлы кунакчыллык символы. Кадерле кунакларны чәк-чәк белән каршы алу кvнелле. Үзенен якты тосе белән ул татар халкынын, шулай ук Мордовия жирендә яшәvче барлык татарларнын кунакчыллыгын,

дуслыгын һәм бердәмлеген символлаштыра.
«Кош теле», катлама, урама, розочкалар дип тә йортәләр. Десерт, чонки ул шикәр, бал һәм майдан ясалган. Шикәр пудрасы сибеп тә бирәләр.Чәй һәрвакыт татарларда яраткан, чын-чынлап халык эчемлеге дип санала, ә чәй табынынын гадәти булмаган ритуалы була.
Татар халкынын бәйрәм ризыгы, камыр ашы – чәк-чәк. Эрбет яки урман чикләвеге зурлыгында кисәклеп, кайнап торган майда пешерелә һәм кайнар бал белән катырыла. Туй очен чәкчәк зур итеп ясала, остенә вак-вак конфетләр куела. Камырны токмач шикелле кисеп ясалган торе – «Бохар кәләвәсе» дип атала.
Ә менә чәкчәк пешерергә осталык нәселдән килә, икән. Буыннан килгән әлеге энже-мәржәннәргә тин ашамлыкны әнисе - кызына, оныкларына ойрәтә. Элек-электән әгәр кунакны vзен пешергән чәкчәк белән сыйласан, сине хормәткә лаек дип санаганнар.
Тагы татарлар бик тә чәй ярата. «Татарларнын топ ризыгы - дvрт чынаяк эчәргә кирәк булган чәй, бай булмаган татарларда - бал белән, дип яза этнограф Карл Фукс XIX гасырда ук – һәр хәлле татарнын vз самавыры бар». Бу эчемлек - табын рухы, татар кунакчыллыгы символы. Тагын чәй - тынычлык, аралашу эчемлеге. Юкка гына дипломатлар борынгы заманнардан нәкъ менә чәй табыны артына жыелып аралашканнар. Татарларда чәй әзерләvгә ижади якын килеп, яратып башкаралар.

**Наилә НАСЫРОВА** *тәржемәсе*